**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛАН-БЕКСЕРСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422723, Республика Татарстан, Высокогорский район,
с. Алан-Бексер, ул. Центральная, 19

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АЛАН-БӘКСӘР
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
422723, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Алан-Бәксәр авылы, Үзәк ур., 19

тел./факс 8(84365) 63-9-51, e-mail: AlanB.Vsg@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**25 ноябрь 2024 г.** **№ 15**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге башкарма комитетының 31.10.2019 елның 75 номерлы «Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге Башкарма комитетының баш бухгалтеры һәм бухгалтерларының, бюджет өлкәсенең Бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым оешмалары хезмәткәрләренең, хәрби исәп хезмәткәрләренең хезмәтенә түләүне оештыру һәм шартлары турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының "Үзәкләштерелгән бухгалтерияләр җитәкчеләренә һәм белгечләренә, шәһәр һәм авыл җирлекләре бухгалтерларына хезмәт хакы түләү турында" 07.10.2024 № 03-12/7086 хаты нигезендә һәм муниципаль берәмлек учреждениеләре хезмәткәрләренә хезмәт хакы түләү системасын камилләштерү максатларында, Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ**

1. 2025 елның 1 гыйнварыннан Башкарма комитетның 2019 елның 04 декабрендәге 75 нче номерлы «Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге Башкарма комитетының баш бухгалтеры һәм бухгалтерларының, бюджет өлкәсенең Бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым оешмалары хезмәткәрләренең, хәрби исәп хезмәткәрләренең хезмәтенә түләүне оештыру һәм шартлары турында» карары белән расланган баш бухгалтерларныү һәм үзәкләштерелгән бухгалтерияләр хезмәткәрләренең айлык вазыйфаи окладлары күләмнәрен арттырырга.

2. Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге Башкарма комитетының 2019 елның 04 декабрендәге 75 нче номерлы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге Башкарма комитетының баш бухгалтеры һәм бухгалтерларының, бюджет өлкәсенең Бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым оешмалары хезмәткәрләренең, хәрби исәп хезмәткәрләренең хезмәтенә түләүне оештыру һәм шартлары турында» " (Башкарма комитетның 30.09.2020 № 26, 16.12.2022 № 12, 21.03.2023 № 7, 24.06.2024 № 6 карарлары редакциясендә) карары белән расланган «Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге баш бухгалтеры һәм бухгалтерларының (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) хезмәтенә түләүне оештыру һәм шартлары турындагы нигезләмә”гә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

2.1. “Бухгалтерларның вазыйфаи окладлары түбәндәге размерда куела” таблицасында 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| Вазифа | Халык саны түбәндәгечә булган муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетлары |
|---|---|
| | 3,5 мең кешегә кадәр |
| Баш бухгалтер (1 ст.) | 25 700 |

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адрес буенча һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы» на: http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Башкарма комитет җитәкчесе
Алан-Бәксәр авыл җирлеге З.Р.Гарифуллина